**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Иске Иштирәк авыл җирлеге составына керүче Ялтау торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

2018 елның 18 ноябре №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2018 елның 18 ноябрендә «2019 елда Лениногорск муниципаль районының Иске Иштирәк авыл җирлеге Ялтау авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчесеннән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

- тапшырылган вәкаләтләр нигезендә җирлекнең суүткәргеч мөлкәтен ремонтлау объектларының расланган исемлеге нигезендә суүткәргеч мөлкәтне тоту;
- урамнарны яктыртуны оештыру;
- авыл җирлегенең торак пунктлары чикләрендәге юлларны карап тоту;
- җирлек территориясен төзекләндерү һәм яшелләндерүне оештыру.

Әйе Юк".

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 47 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнарның саны 47.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен 47 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде; "Юк" позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде. .

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Иске Иштирәк авыл җирлеге составына керүче Ялтау торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес.

2. Лениногорск муниципаль районының Иске Иштирәк авыл җирлеге Ялтау авылы җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2019 елда үзара салым кертүгә 500 сум күләмендә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме?

- тапшырылган вәкаләтләр нигезендә җирлекнең суүткәргеч мөлкәтен ремонтлау объектларының расланган исемлеге нигезендә суүткәргеч мөлкәтне тоту;

- урамнарны яктыртуны оештыру;

- авыл җирлегенең торак пунктлары чикләрендәге юлларны карап тоту;

- җирлек территориясен төзекләндерү һәм яшелләндерүне оештыру - кабул ителгән.

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Иске Иштеряк ав., Мәктәп ур., 15 йорт; Бакирово ав., Нагорная ур., 38 й.д.Ялтау ур., Мир ур., 27 й.б., Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырырга.http://leninogorsk.tatarstan.ru

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Иске теряк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы, җыенда рәислек итүче
Н.Ә.Мәҗитов